**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ**
**ТЕЛӘЧЕ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОН СОВЕТЫ**
**(IV чакырылыш)**

чираттан тыш утырыш
КАРАРЫ

30 май 2022 ел № 130 Теләче авылы

Теләче муниципаль районы Советының 2016 елның 17 июнендәге 55 номерлы «Татарстан Республикасы Теләче муниципаль районы территориясендә тышкы реклама һәм мәгълүмат чараларын урнаштыру турында» карарына үзгәрешләр кертү хакында

«Реклама турында» Федераль законның 19 статьясына үзгәрешләр кертү хакында» 2022 елның 16 апрелендәге 106-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә, Теләче муниципаль районы Советы карар итте:

1. Теләче муниципаль районы Советының 2016 елның 17 июнендәге 55 номерлы «Татарстан Республикасы Теләче муниципаль районы территориясендә тышкы реклама һәм мәгълүмат чараларын урнаштыру турында» карарына (16.02.2021 № 36 карар редакциясендә) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

Теләче муниципаль районы территориясендә тышкы реклама һәм мәгълүмат чараларын урнаштыру турында Нигезләмәгә:

а) 5.12.5 пунктында "5.1-5.7 өлешләре" сүзләрен "5 өлештә реклама конструкциясен урнаштыру һәм эксплуатацияләү өчен күпфатирлы йорттагы урыннар милекчеләренең гомуми мөлкәте, 5.1, 5.6, 5.7 өлешләрендә файдаланылган очракта" сүзләренә алыштырырга.

2. Әлеге карарны гамәлдәге законнар нигезендә бастырып чыгарырга.

3. Әлеге карар гамәлдәге законнар нигезендә үз көченә керә.

Теләче муниципаль районы Башлыгы Н.Н. Хаҗипов

МУНИЦИПАЛЬНОЕ ОБРАЗОВАНИЕ ТЮЛЯЧИНСКИЙ МУНИЦИПАЛЬНЫЙ РАЙОН РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН
ТЕЛӘЧЕ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
СОВЕТ ТЮЛЯЧИНСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
ТЕЛӘЧЕ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОН СОВЕТЫ